Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 12 (25)

19 апрель 2012 ел

## • Ике авыз сүз

16 апрель көнне ректоратның чираттагы утырышы үтте. Көн тәртибендә биш сорау иде. Беренчеләрдән булып, университет порталын инглиз теленә тәрҗемә итү эшенең барышы турында тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов чыгыш ясады. Бүгенге көнгә инде төп бит һәм бүлекләргә караган мәгълүмат тәрҗемә ителгән. Ректор И.Гафуров КФУ сайтында вузны презентацияләгән аерым битнең булмавын билгеләп үтте һәм якын арада аны ике телдә дә булдырырга кирәклеген әйтте. Моннан тыш, ректор сайтны тагын да кызыклырак, мәгълүматларга байрак итәргә, ә инглиз телендәге вариантында «институт» сүзенә аңлатма бирергә кушты. Ник дигәндә, «институт» сүзе чит илләрдә башкачарак мәгънәне белдерә һәм, чит илдән хезмәттәшләр белән эшләгәндә, аңлашылмаучанлыклар килеп чыга.

Икенче булып сүз икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллинга бирелде. Ул КФУ ның Үсеш программасының үтәлеше турында хисап тотты. Үз чыгышында берничә яңа килешү турында сөйләде. Шулай ук университетта Идел буе федераль округы контроль идарәсе тарафыннан үткәрелә торган тикшерү нәтиҗәләре һәм тикшерү барышында туган кайбер сораулар турында әйтеп үтте. Мәсәлән, КФУ ның кайбер бүлекләрендә эшчәнлек турындагы нигезләмә юк, 1 июньгә кадәр аларны төзеп куярга кирәклеген белдерде. И.Гафуров исә әлеге нигезләмәләрне төзергә һәм сайтка урнаштырырга тәкъдим итте.

КФУ ның Тарих институты директоры Р.Хәйретдиновның чыгышы әлеге бүлекчәнең үсеш программасының максатчан күрсәткечләренә төзәтмәләр кертү белән бәйле иде. Ул башкарылган эшләрне санап үтте һәм бу мәсьәләгә карата фикер алышу булды.

Фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев КФУ ның институт-факультетларында фәнара, биомедицина һәм кара алтын-газ өлкәләрендә тикшеренүләр, инженерлык фәне юнәлешендә белгечләр әзерләү кебек мөһим мәсьәләләр турында сөйләде. Ул үзенең чыгышында әлеге юнәлешләрнең өстенлекле булуын, билгеле бүлекләрнең теге яки бу юнәлеш буенча уртак тикшеренүләр алып бара алуын ассызыклап үтте. Фикерне дәвам итеп, И.Гафуров университетта фундаменталь медицина үсеше турында сөйләде. Ректор сүзләреннән аңлашылганча, бу юнәлеш буенча Төбәгара клиник-диагностик% үзәк (МКДЦ) белән хезмәттәшлек итү планлаштырыла. Аның КФУ составына керүе дә бик мөмкин. Университетның медицина корпусы төзелешенә бәйле проект-смета документлары инде әзер.

Алга таба административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе А.Хашов чыгыш ясады. Ул КФУ үткәргән яки катнашкан чараларга бәйле җитешсезлекләрне бетерү мәсьәләләренә басым ясады. Бу максатны күздә тотып, И.Гафуров нинди дә булса чараны оештыруда аерым бер җаваплы кешене билгеләргә кирәк, дип киңәш итте.

Утырышны Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры Р.Латыйпов тәмамлады. Ул «Программалы инженерия» һәм «Гамәли математика» юнәлешләре буенча бакалавриат ачылу турында сөйләде. Ректор әлеге юнәлешләрдә магистрлык программалары да ачарга мөмкин һәм кирәклекне әйтте.

• • • •

Бүген тантаналы рәвештә КФУ ның Гыйльми совет утырышы уза. Биредә Гёттинген университеты профессоры Вернер Лефельдтка «Казан университетының Мактаулы докторы» дигән дәрәҗәле исем бирелә. Немец галиме Вернер Лефельдт – Казан университеты тарихи елъязмасын өйрәнүгә зур өлеш керткән абруйлы шәхес. Ул бөек немец математигы Карл Гаусcның архивын тикшерә, Гёттинген университетында эшләгән бу галимнең заманында дөньякүләм мәгълүм Казан университеты профессорлары Н.И.Лобачевский һәм И.М.Симонов белән язышкан хатларны, документларны өйрәнә.

• • • •

Кичә, ягъни 18 апрель көнне университетның юридик факультетында вузара «түгәрәк өстәл» үтте. «Гаилә хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклауның актуаль проблемалары» дип аталган әлеге чарада Татарстан Республикасы буенча ЗАГС аппараты җитәкчесе Э.Зарипова да катнашты.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



# «Ягымлы яз»да юбилей!

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Татар студентларының «Ягымлы яз» фестивале туу, иң беренчеләрдән булып, «Мәгърифәт» газетасы вәкилләре, «Азатлык» яшьләр берләшмәсе һәм, гомумән, татар яшьләренең тырышлыгына бәйле.

Казан шәһәренең балалар һәм яшьләр комитеты бу фикерне күтәреп ала. 1993 елның апрель аенда татарның талантлы студентлары инде халык сәнгатенең җәүһәрләрен сәхнәгә күтәрә. Әлеге фестиваль, республика киңлекләре белән генә чикләнмичә, үзенә төрле өлкәләрдәге татар студентларын берләштерә. Хәзер инде һәр елның апрель аенда Уфа, Самара, Саранск, Төмән, Ижау шәһәрләрендәге, шулай ук Татарстанның барлык уку йортларында белем алучы татар студентлары Казан мэриясе тарафыннан үткәрелгән «Ягымлы яз»га ашкына. Әлеге фестивальне оештыручылар һәм башлап йөрүчеләр дип без «Идел» яшьләр үзәге» дәүләт учреждениесен, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетын әйтә алабыз.

Быел исә «Ягымлы яз» татар студентларының ачык Казан милли иҗат фестивале үзенең егерме яшьлек юбилеен билгеләп үтте. «2012 ел ЮНЕСКО тарафыннан «Милләтләр елы» дип игълан ителгәнлектән, XX иҗат фестивале «Күп милләтле Казан» дип аталды», – ди оештыручыларның берсе булган Казан шәһәре башкарма комитетының телләрне үстерү һәм иҗтимагый бәйләнешләр бүлеге хезмәткәрләре. Шул уңайдан Чит ил студентлары һәм аспирантлары ассоциациясе фестивальнең кунаклары һәм актив катнашучылары иде. Оста алып баручыларыбыз Азат Фазылҗанов һәм Әбри Хәбриләр янында татарча сөйләшүче Африка һәм Казакъстаннан килгән студентларны күрү кызык та, сокландыргыч та иде. Кичәдә башка елларның җиңүчеләре, инде татар эстрада сәнгатендә үз юлларын тапкан җырчыларыбыз да катнашты. Лилия Муллагалиева, Сөмбел Билалова, Ильвина, Алсу Фаракшина, Илмира Нәгыймовалар үзләренең җырлары белән катнашучыларны канатландырдылар.

Безнең Казан федераль университетыннан да күп кенә студентлар чыгыш ясады һәм җиңүгә иреште. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында укучы көчле, профессиональ катнашучы көндәшләр янында безнең Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге студентлары кебек үзешчәннәр дә үзләрен сынатмадылар.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • «Интеллектуаль яз – 2012»

# Көчеңне сынап кара!

**Рамил ХАННАНОВ**

16 апрельдән 21 енә кадәр уку йортыбызда КФУ студентлары оешмалары һәм берләшмәләре советы оештырган «Интеллектуаль яз - 2012» фестивале уза.

Һәр студент яки аспирант, үзе белем алган институт-факультет данын яклап, төрле интеллектуаль чарада көчен сыный ала. Иң күп балл җыйган бүлекләр 3 призлы урын буенча бүләкләнә. 16-19 апрель көннәрендә Дебатлар уза. Шулай ук 16 апрель – «Эрудит», 17 се – «Нәрсә? Кайда? Кайчан?», 18 е – «Тарихка кер», бүген, ягъни 19 ы 17 сәгать 40 минутта II корпусның 218 бүлмәсендә «Рус телен беләсеңме?» дип аталган бәйге үткәрелә. Иртәгә исә «Казан университеты серләре» чарасы шул ук корпусның 108 бүлмәсендә иртәнге 10 да башлана.



Алия Галимуллина фотосы

# «Ягымлы яз»да юбилей!

**Башы 1нче биттә.**

Театр юнәлеше, нәфис сүз номинациясендә Алсу Хафизова – III урын, Алисә Билалова I урынныяулады(җитәкчеләре–Д.Хөснетдинов). Конферанс номинациясендә «Илһам» төркеме II урынга лаек булды (җитәкчесе – А.Билалова). Хореография юнәлешендә дә катнашучыларыбыз һәм җиңүчебез бар. «Яшьлек» бию төркеме сайлап алу турларында уңышлы гына чыгыш ясаса, «Каз канаты» бию төркеме I урынга ук күтәрелде (җитәкчеләре И.Биктаһиров). Мода театры юнәлешендә «Tatarstyle» мода студиясе – III урын (җитәкчесе – Р.Сәләхова), музыкаль юнәлеш, уен кораллары номинациясендә Ләйсән Мөхәммәтҗанова – II урын (җитәкчесе – Д.Надыйрова), музыкаль юнәлеш, вокаль ансамбльләр номинациясендә «Сәлам» фольклор ансамбле – III урын (җитәкчесе – Л.Әхмәтова), «Өмет» вокаль ансамбле II урынны (җитәкчесе – Г.Әкбәрова) яулады.

«Ягымлы яз» елдан-ел үзенең талантлы татар студентлары белән сөендереп тора. Тышта гына түгел, безнең һәрберебезнең дә күңелендә яз бүген, дип үзенең шатлыгы белән уртаклашты һәм җыр бүләк итте жюри рәисе, Татарстанның халык артисты, Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты доценты Римма Ибраһимова.

Бик күп шәһәрләр, вузлар арасында әлеге фестивальдә катнашкан һәм зур җиңүләр яулаган КФУ студентларына афәрин! Алга таба да зур уңышлар аларга.

**Заман талəбе**

# «IT-авыл»да яшик!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Узган атнада университет җитәкчелеге информатика буенча XXIV Бөтенроссия олимпиадасының финалына үтүчеләр белән очрашты. IT-паркта үткән чарага бик күп төбәкләрдән мәктәп укучылары килгән иде.


Алия Галимуллина фотосы

КФУ җитәкчелегенең олимпиадада катнашучылар белән очрашуы да очраклы түгел. Төп максат – үзебезнең федераль университетка мәгълүмати технологияләр белән чын-чынлап кызыксынучы укучыларны җәлеп итү. Әйтергә кирәк, бу өлкәдә кадрлар җитмәү үзен нык сиздерә. Казанда ел саен югары уку йортларын тик 500 гә якын шундый белгеч тәмамлый. Республика күләмендә төзеләчәк «IT-авыл»ның тулы көчтә эшләп китүе өчен дә Татарстанда ел саен мәгълүмати системалар белән камил эш итүче 1-2 мең белгеч әзерләнергә тиеш. «IT-авыл» проектын 5-7 ел эчендә тормышка ашырып бетерергәуйлыйлар.Фәнни шәһәрчектә барлык кирәкле төзелеш объектлары да булыр дип көтелә: торак йортлар, юллар, балалар бакчалары, поликлиника һ.б. Ул гаиләләре белән барлыгы 20 мең белгечкә исәпләнелә. Ректор Илшат Гафуров искәртеп узганча, шушы өлкәдә белем алу киләчәктә бик зур мөмкинлекләр бирәчәк. Мәгълүмати технологияләр бүгенге көндә башка бик күп фәннәрнең нигезе булып тора. Университетыбызның шушы юнәлештә эшли торган институт директорлары чыгышларын тыңлаганнан соң, шуны әйтергә була: информатика белән яхшы таныш һәм программалаштыру эшләрен бернинди авырлыксыз башкарып чыга алучы студентларның, киләчәктә тиешле хезмәт хакы алып, үсештә булган компанияләрдә эшләү мөмкинлекләре башка белгечлекләрнекенә караганда күпкә зур.

Ректор очрашуны: «Һөнәр сайлау ул – тормыш юлдашын сайлау белән бер. Шуңа күрә киләчәктә хезмәт итәчәк өлкәне ашыкмыйча, уйлап, дөрес максатлар куеп сайлый белергә кирәк», – дигән сүзләр белән тәмамлады. Чараның рәсми кызыксындыру өлешеннән соң олимпиадага килүчеләрне университетның музейлары, институтлары белән таныштырдылар.

**Өйрәтәләр мәктәпләрдә**

# Бөек мәгърифәтче юлыннан

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,**
Экология һәм география институты ассистенты

Узган атнада Казанның 81 нче мәктәбендә яшүсмерләрнең Каюм Насыйри исемендәге X Төбәгара фәнни-тикшерену укулары узды.

Табигать фәннәре һәм гуманитар юнәлешләр буенча 13 секция эшләде. 9-11 сыйныфларда белем алучы 178 укучының берләштергән фәнни чарага Татарстаннан гына түгел, Чувашия һәм Мордовия республикаларыннан, Саратов, Оренбург, Пенза өлкәләреннән дә килгәннәр иде. Җиңүчеләрне бүләкләү Г.Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театрында үтте. Казан федераль университетыннан аларны оештыру комитеты рәисе, Экология һәм география институты профессоры Илгизәр Гайсин, Филология һәм сәнгать институты профессорлары Рәгъде Халитов һәм Миңгол Галиев һ.б. сәламләде.



**Җиңүләр һәм табышлар**

# Ярминкәдә күргәннәр

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Узган атнада шәһәребезнең Күргәзмәләр үзәге «Казан ярминкәсе»ндә «Белем бирү. Карьера» дип аталган XII махсус күргәзмә өч көн буена республика яшьләрен, ата-аналарны, мәктәп, училище, техникум, вуз укытучыларын үзенә тартып торды.





■ Җиңүчеләр: Т.Дыганова (уңнан икенче), Г.Гәрәева (уртада)

Моңа чит илләрдән дә, Россия, Татарстанның төрле шәһәрләреннән килгән вәкилләр үз уку йортлары турында әзерләнгән бай мәгълүматлы экспозицияләре һәм бирелгән һәр сорауга бик игътибарлы булып, тулы җаваплар бирүләре дә; теләгән кешегә үзебездә генә түгел, ә Россиянең барлык шәһәрләрендә кирәк булган белгечлекләрне Вакансияләр ярминкәсендә эзләп табарга мөмкинлек булуы да сәбәп булгандыр. Күргәзмәдә теләгән кешеләргә БДИ һәм БРИ тапшырып карау һәм БДИ бланкларын тутырырга өйрәтү буенча практикум оештырылу да матур гадәткә кереп бара.

КФУ тарафыннан тәкъдим ителгән «Чиста су. Казан – 2012» экологик эшкәртмә күргәзмәгә килүчеләрдә зур кызыксыну уятты. Проектларның берсе – «Урта Кабан күлен яңарту», ә икенчесе – «Казансу елгасының уңъяк ярында Универсиада паркы концепциясе» – Бөтенроссия күләмендә үткәрелгән «Иң яхшы парк идеясе» конкурсы җиңүчесе. Бу эшләр профессор Н.Минһаҗеваның фәнни җитәкчелегендә башкарылган.

КФУ күргәзмәсендә шулай ук биология һәм туфракны өйрәнү факультетының микробиология (профессор Р.Наумова җитәкчелегендә «Биосенсор» дигән эшкәртмә), генетика (доцент Л.Фролова җитәкчелегендә «Сулыкларны биоиндикацияләү ысуллары» эшкәртмәсе) кафедраларыннан, шулай ук Икътисад һәм финанс институтыннан да катнаштылар. Бу эшкәртмәләр киң җәмәгатьчелекне, ТР депутатларын һәм фәнни-җитештерү, проект оешмалары җитәкчеләрен дә кызыксындырды.

Күргәзмә кысаларында үткәрелгән эшлекле программаның әһәмиятле өлеше булган тагын да байрак һәм нәтиҗәләрәк булды. Фәнни-тикшеренү, укыту-методик, тәрбия эшләре һәм укытучының җәмәгать эшчәнлеге турындагы материаллары, ягъни портфолиосына экспертиза үткәрелде.Эксперт комиссиясе тәкъдим ителгән фәнни-популяр лекцияләрнең видеороликларын өйрәнде. Иң күп балл җыйган ун укытучы йомгаклау этабына чакырылды. Шул рәвешле, югары уку йортларында эшләүче иң яхшы укытучыларны барлау һәм бүләкләү максатыннан, III Республика конкурсының финалы үткәрелде. Татарстанның 11 югары уку йорты укытучылары катнашкан бу конкурста Филология һәм сәнгать институты коллективы югары нәтиҗәләргә иреште. Музыка сәнгате бүлеге доценты Елена Дыганова – I дәрәҗә диплом, ә татар филологиясе бүлеге доценты, конкурста бердәнбер татар телендә чыгыш ясаучы һәм дәрес күрсәтүче Гөлүсә Гәрәева Гран-прига лаек булды.

● Җиңүнең 67 еллыгына

# Дәһшәтле еллар кайтавазы

Роза ХӘМИТОВА

Заманында безнең университетта белем алган Роза Хәмитова – сугыш елы баласы. Аның хатирәләрендә дәһшәтле сугыш нинди эз калдырган?! Юк, аның гына түгел, ә бөтен сугыш чоры балаларында... Көндәлек битләрендә – ачы хакыйкать.

*(Дәвамы. Башы алдагы санда.)*

***

Әни мәктәптә, ә мин әби белән өйдә торам.

Шимбә көнне кызыклы тормыш башлана. Иртәгә якшәмбе һәм зур базар булачак. Кич белән еракгагы апайлар, әбиләр, бабайлар килә. Алар бездә куна. Күршеләрдә дә, Мәтрүнә, Фекла апайларда да кунаклар була.

Өстәлдә самовар жырлап утыра. Өй эчендә аның зәңгәрсу төтене йөзә. Кояшның киң нуры тәрәзәдән ишеккә кадәр сузылган, шуның өстендә алтынсу тузан бөртекләре биешә. Көн үзәгенә кадәр самовар шулай пыфылдап, пар атып утыра бирә. Бабайлар, әбиләр китә, кире кайталар һәм барысы да чынаяклардан кайнар чәй эчә. Тонык кишер чәе, шулай да барысы да күп итеп эчә, кычкырып сөйләшәләр. Ә төштән соң өй тынып кала – кунаклар китә. Тагын киләсе шимбәгә кадәр әби белән икәү генә калдык инде.

Безгә тагын Нюра килә. Ул әбинең кулыннан тота да: «Минем әбием!» – ди. Ә мин икенче кулыннан тотам да: «Минем әбием!» – дим. Әби көлә, үзенең тавышы калтырый, кызыл бит алмалары селкенә, күзләреннән яшь ага. Әби фронттагы оныгы Ванядан хат көтә. Ә Ваня ул – минем әтинең дусты.

*1942 ел. Октябрь*

***

Бикәй авылында тау башында минем әтинең әнисе – тәтәемнең йорты бар. Аның исеме Гайниҗамал. Куллары бәләкәйләр, үзләре кыштырдыйлар. Әни район үзәгенә йомыш белән киткәндә, мин тәтәемдә калам. Төнлә ул үзенең кытыршы куллары белән минем аркамнан сөя, чәчләремнән сыйпый. Аның янында тыныч һәм шундый рәхәт. Песи дә бар. Тәтәй песиен бик ярата. Песинең исеме юк, шулай да мин бу йорт хайванын Гөлҗамал песие дип йөрим.

Йорт үзе бик иске инде, алгы ягында – җир идән, кышларын ишегалдын өй кыегына кадәр кар белән тутыра. Хуҗалык Бикәй авылының иң читендә урнашкан, авыл шушы өйдән башлана. Кечкенә генә казан тәрәзәсеннән каен күренеп тора. Ул берьялгызы җилдә тирбәлеп утыра, янәшәсендә агачлар да, йортлар да юк. Миңа ул кызганыч, бик кызганыч.



Фронтта фашистлар белән минем әти генә түгел, ә аның туганы, тәтәемнең тагын бер улы Исмәгыйль абый да сугыша. Авылда барысы да мине шул Исмәгыйль абыйга охшата.

Тәтәемнең мин ишегалдында да татарча сөйләшәм, ә эбидә, руслар яшәгән урамда – русча.

*1943 ел.*

***

Тәтәй авырый. Без хәзер анда яшибез. Сәкедә йоклыйбыз. Ялтырап тора торган тимер шарчыклы караватыбыз да әлеге салам түбәле йортка күчте. Монда идән астында бакалар яши, алар күгәрченнәр кебек гөрләшә, ә мич артында чикерткә сайрый. Идәндә кәҗә һәм сарык бәтиләре сикерешә. Кәҗә бәтиләре бигрәк шуклар. Алар җыештырып куелган урынга менеп, ак тышлы мендәрләргә ятырга яраталар. Безнең белән ике туган апам Гөлҗиһан да яши. Ул зур инде, әнисе үлгән, әтисе – фронтта. Гөлҗиһан апа китап укырга ярата, хәтта төнлә дә юрган бөркәнеп укый. Ничек, дисезме? Юрган астында аның «тәтек» бар – керосин салынган һәм фитилле кечкенә генә спиртовкасавыт. Әни Гөлҗиһанны орыша, ә ул елый. Моңсу. Өйдә яңалифтә басылган китаплар бар. Миңа аларны укыйлар, мин үзем дә укыштырам. Миңа берәү дә хәреф күрсәтми, ләкин мин аларны таныйм. Моның турында бер кеше дә белми.

*1943 ел. Кыш.*

*(Дәвамы киләсе саннарда.)*

● Фән дөньясында

# Начар гадәтләр модадамы?

Динара ӘХМӘТОВА,
Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрчеләр

20-21 апрель көннәрендә КФУның фәлсәфә факультетында «Кешенең фәлсәфәдә, фәндә һәм диндә күпкырлылыгы һәм камиллеге» дигән халыкара фәнни конференция узa.

Россиянең төрле шәһәрләреннән җыелган галимнәр фәлсәфә өлкәсендә булган ачышлар турында фикер алышачак, тәҗрибә уртаклашачак. 5 секция утырышында барлыгы 60 тан артык доклад тыңланыр дип көтелә. Шулай ук «Хәзерге заман шартларында кеше күпкырлылыкка һәм камиллеккә ирешә аламы?» һәм «Дискурсив оешмалар: гомогенлык һәм гетерогенлык проблемасы» темаларына «түгәрәк өстәл»ләр уздырылачак. Конференция кунакларын мәркәзебез буенча мавыктыргыч сәяхәт тә көтә.

Ничә гасырлар буе җир йөзендәге иң актуаль сорауларга җавап эзли торган фәлсәфә фәне бүгенге көндә дә әлеге тугры юлыннан тайпылмый. Фәлсәфәчеләр замана кешесен аңларга, аның эш-гамәлләренә ачыклык кертергә тырыша.

Хәзерге заманда кеше тиз нәтиҗә һәм матди байлык артыннан куып, иҗади потенциал үсешенә карата игътибарын бөтенләй югалтты. Бу, үз чиратында, җәмгыятьнең социаль һәм мәдәни үсешенә дә зур зыян сала. Конференциягә җыелган галимнәр арасында да әлеге проблеманы күтәрүчеләр байтак.

## *Җитез әңгәмә*

«Кешеләр арасында булган тискәре күренешләргә җавап бирү юлларын эзлибез», – ди конференциядә катнашучыларның берсе – фәлсәфә фәннәре кандидаты, КФУ галиме Рөстәм Хәмит улы Абинов. Аның белән җитез әңгәмә корып алдык.



**– Рөстәм Хәмитович, Сезнең темагыз шактый үзенчәлекле. Каббализм төшенчәсенең асылын аңлату белән бәйле. Ә нәрсә соң ул каббализм?**

– Каббализм – ул борынгы белемнәрнең берсе, иудаизмның бер тармагы. Башта ул дини формада булса, урта гасырларда дини-фәлсәфи юнәлеш ала. Аның нигезендә кешене төп кыйммәт итеп алу, үзгәртергә теләү ята. Каббалистлар яшәешнең мәгънәсе нидә, дигән сорауга җавап эзләп, кеше белән дөнья арасында бердәмлек урнаштырырга омтылалар.

**– Ә темагызның актуальлеге нидә?**

– Дөрестән дә, тема әһәмиятле. Ул бүгенге көндә кешеләр арасында, бигрәк тә яшьләр арасында булган тискәре күренешләрне бетерүгә юнәлтелгән. Нинди күренешләр соң ул, диярсез. Эгоизм, индивидуализм, саранлык, кырыслык, көчләү, агрессивлык – болар бүгенге яшьләрнең характерларын туплаучы сыйфатлар. Кызганычка каршы, начар гадәтләрне үзләштерү модага кереп китте дисәм дә, ялгыш булмас.

**– Рөстәм Хәмитович, ни өчен яшәеш шундый юнәлеш алды соң?**

– Кешедә булган тискәре гадәтләр җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрдән, гаделсезлектән килә. Хәзер төп идеология ул – байлык туплау. Яшьләр дә үз алларына төп максат итеп карьера булдыру, рәхәт яшәү, ләззәт алу һәм боларга ирешү юлларын эзләүне куялар. Әхлак нормалары белән исәпләшеп тору бөтенләй дә юкка чыга. Агрессия, рухсызлык бүген инде мәктәпләрдә үк чәчәк ата башлый. Гаиләләрдәге язгышлар да моның башлангычы булып тора.

**– Шушы хезмәтегездә бу ситуациядән чыгуның нинди юлларын күрсәтәсез?**

– Каббалистлар да бу тискәре күренешләрне кеше тормышыннан алып ташларга чакыра, кешенең аның үзгәртергә кирәк, дигән фикердә торалар. Ләкин моны аңны үзгәртеп кенә бетереп булмый. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне үзгәртергә, төп максат итеп матди байлыкка омтылуны түгел, ә рухи якны кайгыртуны куярга кирәк. Рухсызлык ул – бөтен нәрсәгә дә битарафлык дигән сүз. Җәмгыятебездә булган гаделсезлекне бетерүне, мисал өчен, кешенең хезмәтен бәяли белүдән башларга кирәк.

**– Яшьләр арасында мондый проблеманың аеруча киң үсеш алуын, үзегез ничек аңлатыр идегез?**

– Бу – киң планда карала торган сорау. Наркомания, алкоголизм кебек начар гадәтләрнең алга чыгуы нидән соң? Әлбәттә, эшсезлектән. Эш урыннары булдыру кешене буш йөрүдән азат итә. Ә буш йөргән кеше җинаять юлына да баса, урлаша да башкасын да эшли. Аңны үзгәртеп кенә бу күренешләр юкка чыкмаячак, тормыш шартларын үзгәртергә, кеше белән җәмгыять арасында мөнәсәбәтләрне камилләштерүгә омтылырга кирәк дип уйлыйм.

● Сәнгать



Рамил Гализов фотосы

# Аделаида йолдызлыгы

Гөлшаһидә ДАУТОВА,
ifi.kpfu.ru сайты хәбәрчесе

17 апрель көнне Филология һәм сәнгать институтында сәнгать бүлегенең IV курс студенты Аделаида Исламованың күргәзмәсе ачылды. Яшь талантның иҗаты белән 8 майга кадәр танышырга мөмкин булачак.

Әйтергә кирәк, Аделаида – бүгенге көндә танылып килүче рәссам. Ул халыкара күргәзмәләрдә еш катнаша, рәсем сәнгатен генә түгел, компьютер графикасын да үз итә. Сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы мөдире Расыйх Сәләхов билгеләп үткәнчә, узган ел институтка килгән Минтимер Шәймиев Аделаида иҗатын ошаткан һәм бер картинасын истәлеккә үзенә алган иде. «Ул буяулар белән түгел, ә җаны белән яза. Мондый күргәзмә – бер авторның алга китеше генә түгел ул, ә барча студентларны рухландырган адым. Үсеш өчен барлык шартлары булган институтта Аделаида ирешкәннәргә омтылырга мөмкинлек зур», – диде ул үз чыгышында.

Институт директоры Рәдиф Җамалетдинов, яшь рәссамны котлап, чәчәк бәйләме һәм бүләк тапшырды. «Бездә бүген зур бәйрәм – студентыбызның күргәзмәсен ачабыз. Якын киләчәктә әлеге күргәзмәне Карагандада оештыру көтелә. Аделаиданың уңышлары белән горурланабыз», – диде. Ә ТР ның Рәссамнар берлеге, студентыбызга Россия Рәссамнар берлегенә керүдә ярдәм итеп, уңай бәяләмә бирергә вәгъдә кылды.

● Бәйге

# «Җан тынычлыгы җитми...»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Каләм тибрәтүче яшьләр арасында инде ике ел рәттән үткәрелеп килә торган «Таян Аллага» әдәби конкурсы турында күпләрегезнең ишеткәне бардыр. Быел да бәйге старт алды. Аның шартлары һәм, гомумән, бәйгенең үзе турындагы сорауларга җавап алыр өчен, Вәлиулла хәзрәт Якуповка мөрәҗәгать иттем.



■ Тәүге тапкыр «Таян Аллага» бәйгесен ачу тантанасы.
Вәлиулла хәзрәт Якупов (чыгыш ясый) һәм жюри әгъзалары. 2010 ел.

**– Вәлиулла хәзрәт, «Таян Аллага» әдәби конкурсына ничек нигез салынды һәм ул нинди максатларны күздә тота?**

– Бу конкурс быел инде өченче тапкыр игълан ителде. Ике ел рәттән без аны үзебез генә (Диния нәзарәте) оештырган идек, ә быел аның чикләре тагын да киңәйде: Диния нәзарәте, Милли китапханә, Язучылар берлеге һәм ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты да теләктәшлек күрсәтә. Әлбәттә, иҗади яшьләр арасында хәерлелек, шәфкатьлелек юнәлешендәге әсәрләр күбрәк булдырылсын иде. Без үз алдыбызга яшь көчләрне тупларга һәм дини кыйммәтләргә игътибарларын юнәлтергә дигән максат куйдык.

**– Бүгенге яшьләр үз әсәрләрендә нинди проблемаларга өстенлек бирә һәм конкурска килгән әсәрләрнең эчтәлеге нидән гыйбарәт?**

– Алдагы елларда бәйге әле үзенең беренче адымнарын гына ясады. Башка әдәби конкурслар кебек үк ул шигърият, проза һәм драматургия номинацияләрен үз эченә ала. Күпчелек әсәрләр шигырь формасында языла. Дини кешеләрнең эзләнүләре, тормышы чагылдырылган әсәрләрне очратырга була. Кызганычка каршы, әлегә яшьләр дин кыйммәтләрен тирән рәвештә кабул итми, дини темаларга өстән-өстән генә кагылып китәләр...

**– Ә моның сәбәбе нидә дип уйлыйсыз?**

– Миңа калса, бу мәгълүмат җитмәүдәндер. Иҗат итәргә яратучы яшьләр, рухи бер тирәнлеккә кереп, Ислам дине турында белемнәрен тирәнәйтсеннәр иде. Безнең классик әдәбиятта да суфичыл юнәлештә бик ныклы рухи нигездә язылган әсәрләр бар. Урта гасырлар әдәбиятында шулай ук дини мотивлар күп. Хәзерге заманда әдәбият мондый темаларга бигрәк тә мохтаҗ, рухи эзләнүләргә мохтаҗ. Без яшьләрдән дә шуны көтәбез. Һәм, иманым камил, ул кайчан да булса тормышка ашачак. Дөрес, хәзер дини тематикага кагылышлы әсәрләр бар, ләкин алар ничектер сурәтләү формасында гына.

**– Бәйгедә нинди әсәрләрне күрергә теләр идегез?**

– Иҗат җимешләрендә рухи анализ булсын иде. Ислам диненең матурлыгын күрсәткән әсәрләр, дини булып камилләшкән кешенең хисләрен күрсәткән иҗади әсәрләрне укыйсы килә.

**– Катнашу шартлары турында да әйтеп үтсәгез иде...**

– Бәйгегә әсәрләр татар телендә электрон вариантта кабул ителә. Конкурс өч номинациядә үтә: шигърият, чәчмә әсәрләр, драматургия. Аз күләмле әсәрләр (шигырьләр, кыска хикәяләр һ.б.) өчтән ким булмаска тиеш. Әсәрләр белән бергә конкурста катнашучы үзе турында мәгълүмат, адресын һәм телефон номерын җибәрергә тиеш. Электрон адрес: tayanallaga@yandex.ru. Конкурс июнь аена кадәр дәвам итәчәк.

**– Ә конкурска нәтиҗәне кемнәр ясый?**

– Алдагы елларда без бу эшне элеккеге ТДГПУ ның әдәбият белгечләре белән килешеп, киңәшләшеп башкара идек. Ә быел Язучылар берлеге һәм Разил Вәлиев белән уртак фикергә килеп, даими жюри булдырырга уйлыйбыз. Әдәби конкурс булгач, монда тел белгечләре белән дә хезмәттәшлек итмичә булмый.

**– Бүләкләү өлеше ничегрәк уза?**

– Гадәттә, ул тантаналы рәвештә көз көне үтә, җиңүчеләргә акчалата премияләр бирәбез. Беренче конкурста җиңүчегә, шуңа өстәп, Хаҗга юллама да биргән идек. Финанслау өлешен Диния нәзарәте үзе башкара. Яшь иҗатчыларның әсәрләрен туплап, җыентыклар да бастырып чыгардык.

**– Хәзерге яшьләргә ни әйтерсез, Вәлиулла хәзрәт?**

– Ислам диненең яшәү рәвеше, зур тәгълимат икәнен онытмасыннар иде. Уйлап карасаң, ул бит зур рухи океан. Шуңа карамастан, рухи ләззәт алу бәхетенә халкыбызның бик азчылыгы гына омтыла. Ә безнең аны иҗат аркылы да башкаларга җиткерәсебез, мавыктыру көчен күрсәтәсебез килә. Ислам дине таләпләре буенча яшәсәк, хәләл тормыш алып барсак, гаиләләребез дә бәхетле булыр. Кешеләр җан тынычлыгына ия булыр. Бүген халыкка нәкъ менә рухи байлык, җан тынычлыгы җитми. Минем уйлавымча, яшьләр белән берлектә нәфис формада да шуны халыкка җиткерү – ул бик әһәмиятле адым!

**– Кызыклы әңгәмәгез өчен зур рәхмәт Сезгә!**

● Тәүге адымнар

# Кабат очрашу

**Гөлия ӘХМӘТШИНА,**
Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студенты

Мин кабат күңелемдә һич җуелмас матур хатирәләр калдырган туган мәктәбемдә. Юк, бүген инде мин ак алъяпкычлы гамьсез укучы кыз бала түгел. Мин – практикага кайткан Укытучы! Син, мәктәбем, һич тә үзгәрмәгәнсең. Барчабызны дәрескә җыйный торган шул ук көмеш кыңгырау чыңы, гөлләргә күмелгән чиста, матур класс бүлмәләре, һәр соравыңа җавап бирергә әзер булган, сиңа үз кеше итеп караучы, мәрхәмәтле укытучылар... Бар да таныш, бар да якын, бар да үз! Мин мәктәп буйлап курыкмыйча, һич тә тартынмыйча, «үз мәктәбем», диеп, ышанычлы адымнар белән атлыйм. Беләм, мин монда үз кеше. Чөнки әле минем мәктәптән китүемә дә 4 кенә ел.

Үз мәктәбемә практикага кайтуым белән мин бәхетле идем. Миңа беркетелгән X сыйныф укучылары бик күндәм, акыллы булып чыкты. Без бик тиз уртак тел таптык. Гомумән, безнең Ш.Зиннуров исемендәге Сатыш урта мәктәбе (Саба районы) укучылары үзләренең тәртипле булулары белән аерылып торалар. Дәрес барышында бер генә тапкыр да, бер генә балага да шелтә белдерергә туры килмәде. Минем бераз дулкынлануымны, каушавымны сизсәләр дә, мине уңайсыз хәлгә куймадылар. Аларның күзләреннән: «Каушама, каушама, Гөлия апа, без Сезне һич тә уңайсыз хәлдә калдырмабыз, бар да аңлашыла», – дигән юлларны укып була иде. Дәрес барышында биргән һәр сорауга тулы җавап бирде алар. Чыннан да, укучыларым мине үзләренең якын дуслары итеп күрделәр. Дәресләрдән соң остаз укытучым Рәдиф Мулламөхәммәт улы дәресемә уңай бәяләмә бирде. Аның җылы фикерләре мине тагын да канатландырды, үземә ышаныч уятты. Аңа чын күңелемнән олы рәхмәтемне җиткерәм.

Ике ай вакыт сизелми дә үтеп китте. Яраткан унынчыларым, мәктәбем, укытучыларым белән саубуллашып, кабат белем эстәү юлына – Казан каласына кузгалдым.

Сайлаган һөнәремнең «үземнеке» икәнен исбатлауда ярдәм иткән, гадел, намуслы, чын кеше булырга өйрәткән, төп белем һәм тәрбия биргән өчен, Ш.Зиннуров исемендәге Сатыш урта мәктәбе укытучыларына олы рәхмәт.




## Игътибар!



**25 апрель көнне 18 сәгать 30 минутта** Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Хәй Вахитның **«Беренче мәхәббәт»** драмасын күрә аласыз. Аны сезгә уку йортыбызның инде күптән мәгълүм **«Мизгел» театры** тәкъдим итә. Төп рольләрне Венера Макова һәм Ильнар Галиәхмәтов башкара. Режиссёр – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Марсель Җаббаров. Рәхим итегез!




DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.